ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 186-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 186-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2026 елның 22 августына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2026 елның 22 сентябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 22 июле
№ 669-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш), № 79 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш), 2026, № 25 (I өлеш), № 32 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон),» сүзләрен төшереп калдырырга, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон),» сүзләреннән соң «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон),» сүзләрен өстәргә;

2) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Татарстан Республикасында җирле үзидарә**

1. Җирле үзидарә Татарстан Республикасы конституциячел төзелеше нигезләренең берсен тәшкил итә.

2. Татарстан Республикасында җирле үзидарә – халыкның Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда, башка федераль законнарда, ә федераль законнарда каралган очракларда – Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен (җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне) мөстәкыйль хәл итү өчен үз хакимиятен гамәлгә ашыру максатларында гражданнарның үзоешуының Россия Федерациясе Конституциясе тарафыннан таныла торган һәм гарантияләнә торган формасы.

3. Татарстан Республикасында җирле үзидарә гражданнар тарафыннан турыдан-туры ихтыяр белдерү рәвешләре аша, шулай ук җирле үзидарә органнары аша гамәлгә ашырыла.

4. Җирле үзидарә Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлгә ашырыла.

5. Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә җирле үзидарә органнары Россия Федерациясендә бердәм гавами хакимият системасына керәләр.

6. Җирле үзидарә органнары дәүләт хакимияте органнары системасына керми.

7. Гавами хакимият органнары «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә җирле үзидарә бурычларын хәл итүдә катнашалар.

8. Җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә хәбәрдарлыкны тәэмин итү, шул исәптән җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге бирү гарантияләнә.»;

3) 2 статьяда «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга»;

4) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 статья. **Гражданнарның җирле үзидарәне гамәлгә ашыру хокуклары**

1. Гражданнар җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда җенесләренә, нинди расадан һәм милләттән булуларына, телләренә, чыгышларына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәлләренә, дингә мөнәсәбәтләренә, инануларына, иҗтимагый берләшмәләрдә торуына бәйсез рәвештә бертигез хокукларга ия.

2. Гавами хакимият органнары гражданнарның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе Конституциясе һәм «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»

Федераль закон белән билгеләнгән хокукларын тәэмин итәләр.»;

5) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең хокукый нигезе**

Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, гомумтанылган принциплар һәм халыкара хокук нормалары, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, федераль конституциячел законнар, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең шулар нигезендә чыгарылучы башка норматив хокукый актлары (Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, федераль башкарма хакимият органнарының башка норматив хокукый актлары), Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, башка законнар һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль берәмлекләр уставлары, җирле референдумнарда һәм гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарлар һәм башка муниципаль хокукый актлар тәшкил итә.»;

6) түбәндәге эчтәлектәге $4^1$ статьяны өстәргә:

«$4^1$ статья. **Татарстан Республикасында җирле үзидарәне хокукый җайга салу принциплары**

1. Татарстан Республикасында җирле үзидарә «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән принциплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль берәмлекләр уставларында һәм башка муниципаль хокукый актларда Татарстан Республикасында гавами хакимиятнең бердәм системасына керүче органнарның дистанцион үзара эшчәнлек тәртибе, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышларында дистанцион катнашу тәртибе каралырга мөмкин.»;

7) 5 статьяда:

а) 1 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыру мәсьәләләрен федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә хокукый җайга салу;»;

4 пунктта «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

8) 6 статьяда:

а) 1 һәм 2 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хокукый актлар системасына түбәндәгеләр керә:

1) җирле референдумда, гражданнар җыенында кабул ителгән хокукый актлар;

2) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының хокукый актлары;

3) муниципаль берәмлек башлыгының хокукый актлары;

4) җирле администрациянең хокукый актлары;

5) муниципаль берәмлек уставы белән каралган җирле үзидарәнең башка органнарының һәм җирле үзидарә урындагы затларының хокукый актлары.»;

в) 4 өлештә:

беренче абзацта «җирле референдумда (гражданнар җыенында)» сүзләрен «җирле референдумда, гражданнар җыенында» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «җирле референдумда (гражданнар җыенында)» сүзләрен «җирле референдумда, гражданнар җыенында» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлештә:

беренче абзацта «Җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хокукый актларны үтәмәү федераль законнар һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә җаваплылыкка китерә.»;

д) 7 өлештә «халыкка игълан ителгәннән» сүзләрен «басылып чыкканнан» сүзләренә алмаштырырга;

е) $8^1$ өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$8^1$. Муниципаль хокукый актны халыкка игълан итү дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла»;

3 пунктта «муниципаль берәмлекнең» сүзләре алдыннан «муниципаль хокукый актны» сүзләрен өстәргә;

ж) $8^2$ өлештә «тулы текстны челтәр басмада беренче тапкыр урнаштыру» сүзләрен «челтәр басмада беренче тапкыр урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

з) түбәндәге эчтәлектәге 8□ өлешне өстәргә:

«8□. Башка документларны һәм мәгълүматны халыкка игълан итү, әгәр мондый игълан итү «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган булса, муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү өчен каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

и) 9 өлештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга» сүзләренә алмаштырырга;

к) 10 өлештә «Җирле референдумда (гражданнар җыенында)» сүзләрен «Җирле референдумда, гражданнар җыенында» сүзләренә, «Татарстан Республикасы законында» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән» сүзләренә алмаштырырга;

9) $6^2$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

10) $6^3$ статьяда:

а) исемдә «, муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә «, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә, шулай ук әлеге Законга 1 нче кушымтада каралган исемлеккә кертелгән башка шәһәр округларында һәм муниципаль районнарда мәҗбүри булып тора.» сүзләрен «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә, шулай ук әлеге Законга 1 нче кушымтада каралган исемлеккә кертелгән башка шәһәр округларында һәм муниципаль районнарда мәҗбүри булып тора» сүзләренә алмаштырырга.»;

в) 2 өлештә «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау җирле үзидарә органнары тарафыннан үз инициативалары белән башкарылырга мөмкин.» сүзләрен «җирле үзидарә органнары тарафыннан үз инициативалары белән башкарылырга мөмкин.» сүзләренә алмаштырырга;

11) 7 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләре исемлеге;»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл иткәндә халыкның катнашу рәвешләре, тәртибе һәм гарантияләре;»;

5 пунктта «сайлаулы һәм башка» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) муниципаль хокукый актларның төрләре, аларны кабул итү (бастырып чыгару), халыкка игълан итү, шул исәптән рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе;»;

7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

8 пунктта «, шул исәптән җирле үзидарәнең сайлаулы урындагы затларын халык тарафыннан чакыртып алу, җирле үзидарәнең сайлаулы органнарының һәм җирле үзидарәнең сайлаулы урындагы затларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату нигезләре һәм процедурасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 пунктта «аның үтәлешен тикшереп тору» сүзләрен «җирле бюджет үтәлешен тикшереп тору» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль берәмлек уставы проекты, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт проекты муниципаль берәмлек уставын кабул итү, муниципаль берәмлек уставына

үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы мәсьәлә каралырга кимендә 30 көн кала рәсми бастырып чыгарылырга тиеш, бер үк вакытта күрсәтелгән устав проекты буенча, күрсәтелгән муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алуның муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнгән тәртибе, шулай ук аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе рәсми бастырып чыгарылырга тиеш. Муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен тулысынча күчереп, әлеге уставны шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында кертелгән очракта, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару таләп ителми.»;

г) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль берәмлек уставы, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларының билгеләнгән саныннан өчтән икесе күпчелек тавышы белән кабул ителә.»;

д) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Муниципаль берәмлек уставы, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми бастырып чыгарылырга тиеш һәм алар рәсми басылып чыккан көненнән соң үз көченә керә. Муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлекнең теркәлгән уставын, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында теркәлгән муниципаль хокукый актны муниципаль берәмлекләрнең уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан муниципаль берәмлек уставы, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт хакындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына кертү турында «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган хәбәрнамә кергән көннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга тиеш.»;

е) 8 өлешнең беренче абзацында «(муниципаль берәмлек уставы федераль законнарга туры китерелгән очраклардан, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары вәкаләтләре, аларның вәкаләтләр чоры һәм сайлану тәртибе үзгәрүдән тыш)» сүзләрен «(муниципаль берәмлек уставы федераль законнарга туры китерелгән очраклардан, шулай ук муниципаль вазыйфаларны башкаручы затларның вәкаләтләре, аларның вәкаләтләр чоры һәм сайлану (билгеләнү) тәртибе үзгәрүдән тыш)» сүзләренә алмаштырырга, «, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш.» сүзләрен өстәргә;

ж) 8[1] өлештә:

1 пунктта «(гражданнар җыенының)», «(гражданнар җыены)» сүзләрен

төшереп калдырырга;

2 пунктта «(гражданнар җыены)», «(гражданнар җыенының)» сүзләрен төшереп калдырырга;

з) 9 өлештә «датасын» сүзен «көнен» сүзенә алмаштырырга, «(игълан итү)» сүзен төшереп калдырырга;

и) 10 өлештә «муниципаль хокукый акт белән» сүзләрен «муниципаль хокукый акт кабул итү юлы белән» сүзләренә алмаштырырга, «элек гамәлдә булган» сүзләрен «элек гамәлдә булган» сүзләренә алмаштырырга;

12) 9 статьяда:

а) 7 өлештә «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «Халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 өлешнең беренче абзацында «төзелә» сүзен «гамәлгә куелалар» сүзләренә алмаштырырга;

13) 10 статьяда:

а) 1 өлештә «федераль законнар» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 12 өлештә «федераль законнарда» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлектәге 4 өлешне өстәргә:

«4. Тарихи һәм башка җирле традицияләрне, шулай ук СССР һәм Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре булуны исәпкә алып, муниципаль берәмлек составына керүче аерым торак пунктлар, муниципаль берәмлек уставы нигезендә торак пунктның рәсми символларына ия булырга мөмкиннәр.»;

14) 2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 бүлек. **Җирле үзидарәне оештыруның территориаль нигезләре**

12 статья. **Муниципаль берәмлекләрнең төрләре**

1. Татарстан Республикасының бөтен территориясендә җирле үзидарә шәһәр җирлекләрендә, авыл җирлекләрендә, муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль берәмлекләргә шәһәр җирлеге, авыл җирлеге, муниципаль район, шәһәр округы статусын бирү Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.

3. Җирле үзидарәне территориаль оештыру «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән принциплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

13 статья. **Муниципаль берәмлекләрнең чикләре**

1. Муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләре «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы

законнары белән билгеләнә һәм үзгәртелә.

2. Муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү Татарстан Республикасы законы белән «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә халык, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль дәүләт хакимияте органнары инициативасы белән гамәлгә ашырыла.

3. Муниципаль берәмлекләр чикләрен үзгәртү тиешле муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан белдерелә торган халык фикерен исәпкә алып гамәлгә ашырыла. Әлеге вәкиллекле органнар муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү турындагы мәсьәләнең киләчәктә каралачагы хакында халыкны алдан мәгълүмат белән тәэмин итәргә, шулай ук әлеге мәсьәлә буенча халыкка үз фикерен белдерү мөмкинлеген муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы уставы һәм (яисә) норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә тиеш. Бу чакта, әгәр муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы уставы яисә норматив хокукый акты белән мондый тәртип билгеләнмәгән булса, халык фикере гавами тыңлаулар уздыру юлы белән ачыклана. Бу очракта муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турындагы хәбәр, гавами тыңлаулар уздыру көненә 10 көннән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан халыкка җиткерелә.

4. Муниципаль берәмлекләр чикләрен билгеләү яисә үзгәртү турында Татарстан Республикасы законнары кабул ителгән очракта, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясы нигезендә документларны (алардагы белешмәләрне) күчемсез мөлкәтне дәүләт кадастр исәбенә алу органына җибәрү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

14 статья. **Муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору**

1. Муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору муниципаль берәмлекләрне берләштерүдән, муниципаль берәмлекләрне бүлүдән йә муниципаль берәмлекнең рәвешен үзгәртүдән гыйбарәт.

2. Муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору Татарстан Республикасы законнары белән халык, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль дәүләт хакимияте органнары инициативасы белән «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

15) 3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. **Җирлек, муниципаль район һәм шәһәр округы җирле үзидарә органнарының халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләре. Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыру**»;

16) 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Статья 15. **Халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча шәһәр җирлеге, авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 1 өлеше нигезендә шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлек уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, муниципаль хокукый актлар чыгару;

2) җирлекнең рәсми символларын билгеләү;

3) җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау, җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, муниципаль финанс контролен, шул исәптән җирлек бюджеты үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап төзү һәм раслау;

4) җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

5) салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә җирлекнең салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, гамәлгә кертү, элек кертелгән җирле салымнарын һәм җыемнарын гамәлдән чыгару;

6) муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыру ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү;

7) муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзү, муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү һәм муниципаль йөкләмәне бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан үтәүне финанс белән тәэмин итү;

8) муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр күрсәтә торган хезмәтләргә, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр башкара торган эшләргә тарифлар билгеләү, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса;

9) ишегалды эчендәге территорияләрне үстерү;

10) террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук җирлек чикләрендә террорчылык һәм экстремизм чагылышларын минимальләштерүдә һәм (яисә) алардан килгән зыяннарны бетерүдә катнашу;

11) җирлек чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм алардан килгән зыяннарны бетерүдә катнашу;

12) җирлек территориясендәге муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыру;

14) халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләре буенча кабул ителгән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру.

2. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлеше нигезендә шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

2) җирлектә яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, күпфатирлы йортта урыннарны үзгәртеп коруны һәм яңадан планлаштыруны килештерү турында карар кабул итү, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

3) вәкаләтле участок полициясе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә җирлекнең хезмәт күрсәтелә торган административ участогында эшләү өчен бина бирү;

4) җирлек территориясендә физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, шул исәптән массакүләм спортны үстерүгә һәм аның һәркем өчен мөмкинлеген тәэмин итүгә ярдәм итү, балалар-яшүсмерләр спортын (мәктәп спортын да кертеп) үстерү, җирлекнең рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү;

5) җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

6) җирлекнең архив документларын һәм архив фондларын туплау (формалаштыру), исәпкә алу һәм алардан файдалану, җирлекнең муниципаль милкендәге архив документларын Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары, башка муниципаль берәмлекләр милкенә тапшыру турындагы мәсьәләләрне хәл итү;

7) халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, җирлек китапханәләренең китапханә фондларын туплау һәм аларның сакланышын тәэмин итү;

8) җирләү урыннарын карап тоту;

9) адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адреслар реестрында мәгълүмат урнаштыру;

10) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

11) җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларына хокукы булган затларны ачыклау буенча карарлар кабул итү һәм

чаралар үткәрү, әлеге күчемсез милек объектларына хокукы булган затлар турында белешмәләрне Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен юллау;

12) җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре төзү өчен кирәкле эшләрне федераль закон нигезендә башкаруны тәэмин итү;

13) җирлек милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру;

14) җирлекнең икътисады һәм социаль өлкәсе торышын характерлый торган статистик күрсәткечләрне җыюны оештыру һәм аларны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыру;

15) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру;

16) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләренә һәм мәдәниятенә ярдәм итүгә һәм аларны үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, милләтара (халыкара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

17) җирле традицион халык сәнгать иҗаты үсеше өчен шартлар тудыру, җирлектә халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу;

18) җирлек территорияләре составына керүче торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

19) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре, җирлек халкының ялын, күпләп ялын оештыру хезмәтләре белән тәэмин итү, халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү өчен шартлар тудыру;

20) җирлек милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклап калу, алардан файдалану һәм популярлаштыру, җирлек территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклау;

21) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыру;

22) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү;

23) социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм ихтыяр белдерүгә (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтү;

24) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

25) предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән, шул исәптән инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәүдән гыйбарәт булган Россия Федерациясендә дәүләт контроле

(күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында (куркынычсызлык мониторингы) күрсәтмә бирелергә мөмкин);

3. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 3 һәм 7 өлешләре нигезендә шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлек территорияләре составына керүче торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) булдыруны һәм аларның эшләвен тәэмин итүне, юл хәрәкәтен оештыруны кертеп, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

2) халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм җирлек чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

3) ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру;

4) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым-аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

5) федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;

6) җирлек территорияләре составына керүче торак пунктлар җирләрендә урнашкан кишәрлек урманчылыклары составында төзелә торган урманчылыкларны төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук җирлек территорияләре составына керүче торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру;

7) җирлек территорияләре составына керүче торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше чараларын гамәлгә ашыру;

8) гражданнар оборонасы объектларыннан файдалануга даими әзерлек халәтендә ярдәм итүне, гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм тотуны да кертеп, территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, җирлек халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

9) су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

10) халыкка гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалануны чикләүләр турында мәгълүмат бирү, гражданнарның мондый су объектларына һәм аларның яр полосаларына теләгәндә керә алуын тәэмин итүне дә кертеп;

11) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру.

4. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 1 өлеше нигезендә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлек уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, муниципаль хокукый актлар чыгару;

2) җирлекнең рәсми символларын билгеләү;

3) җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау, җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, муниципаль финанс контролен, шул исәптән җирлек бюджеты үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап төзү һәм раслау;

4) җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

5) салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә җирлекнең салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, гамәлгә кертү, элек кертелгән җирле салымнарын һәм җыемнарын гамәлдән чыгару;

6) муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыру ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү;

7) ишегалды эчендәге территорияләрне үстерү;

8) җирлек территориясендәге муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

9) халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләре буенча кабул ителгән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру.

5. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлеше нигезендә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

2) җирлек территориясендә физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, шул исәптән массакүләм спортны үстерүгә һәм аның һәркем өчен мөмкинлеген тәэмин итүгә ярдәм итү, балалар-яшүсмерләр спортын (мәктәп спортын да кертеп) үстерү, җирлекнең рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү;

3) җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

4) җирлекнең архив документларын һәм архив фондларын туплау (формалаштыру), исәпкә алу һәм алардан файдалану, җирлекнең муниципаль милкендәге архив документларын Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары, башка муниципаль берәмлекләр милкенә тапшыру турындагы мәсьәләләрне хәл итү;

5) җирләү урыннарын карап тоту;

6) адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль

районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адреслар реестрында мәгълүмат урнаштыру;

7) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

8) җирлекнең икътисады һәм социаль өлкәсе торышын характерлый торган статистик күрсәткечләрне җыюны оештыру һәм аларны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыру;

9) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру;

10) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләренә һәм мәдәниятенә ярдәм итүгә һәм аларны үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, милләтара (халыкара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

11) җирлек территорияләре составына керүче торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

12) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре, җирлек халкының ялын, күпләп ялын оештыру хезмәтләре белән тәэмин итү, халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү өчен шартлар тудыру;

13) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыру;

14) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү;

15) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

16) предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән, шул исәптән инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәүдән гыйбарәт булган Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында (куркынычсызлык мониторингы) күрсәтмә бирелергә мөмкин);

6. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 3 һәм 7 өлешләре нигезендә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә

түбәндәгеләр керә:

1) җирлек территорияләре составына керүче торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) булдыруны һәм аларның эшләвен тәэмин итүне, юл хәрәкәтен оештыруны кертеп, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

2) җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләр оештырудан һәм аларның эшчәнлек тәртибен раслаудан, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләүдән тыш, ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру;

3) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым-аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

4) гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына теләгәндә керүен тәэмин итү;

5) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру.

7. Җирле үзидарә органнарының халыкның яшәешен турыдан – туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча әлеге статьяның 1 – 3 өлешләрендә шәһәр җирлекләре өчен каралган, әлеге статьяның 4-6 өлешләре нигезендә авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелмәгән башка вәкаләтләре муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарының халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләре була һәм авыл җирлекләре территорияләрендә тиешле муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә.

8. Әлеге статьяның 1-6 өлешләрендә билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда шәһәр җирлеге, авыл җирлеге җирле үзидарә органнары товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алырга вәкаләтле.»;

17) 15[1] статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

18) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 статья. **Муниципаль районның җирле үзидарә органнарының халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләре**

1. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 1 өлеше нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль район уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, муниципаль хокукый актлар чыгару;

2) муниципаль районның рәсми символларын билгеләү;

3) муниципаль район бюджеты проектын төзү һәм карау, муниципаль район бюджетын раслау һәм үтәү, муниципаль финанс контролен, шул исәптән муниципаль район бюджеты үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә муниципаль район бюджеты үтәлеше турында хисап төзү һәм раслау;

4) муниципаль районның муниципаль милкендәге мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

5) гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль район территориясендә (башкарма хакимиятнең халкы аерым территорияләр халкын медик-санитар тәэмин итү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы карамагындагы медицина оешмаларында медицина ярдәме белән тәэмин ителә торган территорияләнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән территорияләрдән гайре) гражданнарның сәламәтлеген саклауны гамәлгә ашыруда, шул исәптән халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыруда катнашу;

6) муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыру ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү;

7) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль район халкына рәсми мәгълүматны җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын гамәлгә кую;

8) муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзү, муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү һәм муниципаль йөкләмәне бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан үтәүне финанс белән тәэмин итү;

9) муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр күрсәтә торган хезмәтләргә, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр башкара торган эшләргә тарифлар билгеләү, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса;

10) муниципаль район чикләрендә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру;

11) террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук муниципаль район чикләрендә террорчылык һәм экстремизм чагылышларының зыяннарын минимальләштерүдә һәм (яисә) бетерүдә катнашу;

12) муниципаль район чикләрендәге гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм алардан килгән зыяннарны бетерүдә катнашу;

13) муниципаль район территориясендәге муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

14) «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыру;

15) халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләре буенча кабул ителгән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру.

2. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның

гомуми принципларын турында» Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлеше нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә муниципаль район чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

2) полициянең участок вәкаләтлесе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә муниципаль районның хезмәт күрсәтелә торган административ участогында эшләү өчен бина бирү;

3) муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (аны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирүдән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

4) муниципаль район территориясендә физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, шул исәптән массакүләм спортны үстерүгә һәм аның һәркем өчен мөмкинлеген тәэмин итүгә ярдәм итү, балалар-яшүсмерләр спортын (мәктәп спортын да кертеп) үстерү, муниципаль районның рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү;

5) каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү чараларын, аларның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп, үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыру;

6) муниципаль район составына керүче җирлекләр халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

7) муниципаль архивны булдыру һәм карап тоту, җирлекләрнең архив документларын һәм архив фондларын саклауны да кертеп;

8) җирлекара китапханәләр тарафыннан халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, аларның китапханә фондларын туплау һәм аларның сакланышын тәэмин итү;

9) муниципаль район территориясендә җирлекара җирләү урыннарын карап тоту;

10) федераль закон нигезендә муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре төзү өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү;

11) муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру;

12) муниципаль районның икътисады һәм социаль өлкәсе торышын характерлый торган статистик күрсәткечләрне җыюны оештыру һәм әлеге

күрсәткечләрне Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыру;

13) муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль районның муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре, муниципаль район составына керүче җирлекләр хезмәткәрләренә һөнәри белем бирүне һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыру;

14) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләренә һәм мәдәниятенә ярдәм итүгә һәм аларны үстерүгә, милли азчылыкларның хокукларын гамәлгә ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

15) муниципаль район составына керүче җирлекләрдә җирле традицион халык сәнгате иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, муниципаль район составына керүче җирлекләрдә халык сәнгате кәсепләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу;

16) торак пунктлар чикләреннән тыш муниципаль район чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

17) муниципаль район составына керүче җирлекләрдә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәтләре, ял итүне оештыру хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

18) муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, муниципаль район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклау;

19) муниципаль район составына керүче җирлекләрдә авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыру;

20) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү;

21) социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган коешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм ирекле ярдәмчелеккә (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтү;

22) муниципаль район территориясендә гамәлгә ашырыла торган фәнни, фәнни-техник һәм инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү, муниципаль районның фәнне популярлаштыруга юнәлдерелгән программаларын кабул итү, чараларын оештыру һәм үткәрү;

23) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

24) Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль контрольнең түбәндәге төрләрен гамәлгә ашыру:

а) муниципаль район территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың йөкләмәләрен үтәвенә муниципаль контроль;

б) муниципаль район территориясендә җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контроль;

в) муниципаль район территориясе составына керүче торак пунктлар чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль;

г) муниципаль район территориясендә муниципаль җир контроле;

д) муниципаль район территориясендә муниципаль урман контроле.

3. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 3 һәм 7 өлешләре нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) булдыруны һәм аларның эшләвен тәэмин итүне, юл хәрәкәтен оештыруны кертеп, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

2) халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм муниципаль район чикләрендәге җирлекләр арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

3) аларга карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларын, транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, муниципаль районның социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшләү һәм раслау;

4) муниципаль район чикләрендә әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын оештыру, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү;

5) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программаларны раслау һәм гамәлгә ашыру, муниципаль район чикләрендә урыннары муниципаль торак фонды тәшкил итә торган күпфатирлы йортларга энергетика тикшерүен уздыруны оештыру, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда каралган башка чараларны оештыру һәм үткәрү;

6) җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләр оештыруны һәм аларның эшчәнлек тәртибен раслауны кертеп, ритуаль хезмәтләр күрсәтүне

оештыру, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү;

7) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым-аерым туплау), җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;

8) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карап чыгуларны гамәлгә ашыру һәм мондый карап чыгулар барышында ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирү, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының төзелешне планлаштыру турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килү һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итү турында хәбәрнамә юллау, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килмәү һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итмәү турында хәбәрнамә, төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының муниципаль район территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә урнашкан индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамәләр, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны тиешле таләпләргә туры китерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерүне гамәлгә ашыру яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда тиешле таләпләргә туры китерү, капиталь төзелеш объектын авария хәлендә дип тану һәм аның сүтелергә тиешлеге йә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда реконструкцияләнергә тиешлеге турында карар кабул итү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $5^1$ статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар уздыру;

9) җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның икенче төренә үзгәртү турында карар кабул итү, хосусый милектәге җир кишәрлекләрен, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, бер категориядән икенче категориягә күчерү турында карар кабул итү;

10) федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;

11) Реклама турында Россия Федерациясе законнары нигезендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау, муниципаль район территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтләр бирү, мондый рөхсәтләрне юкка чыгару, муниципаль район территориясендә рөхсәтсез урнаштырылган реклама конструкцияләрен демонтажлау турында күрсәтмәләр бирү;

12) гражданнар оборонасы объектларыннан файдалануга даими әзерлек халәтендә ярдәм итүне, гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-

төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм тотуны да кертеп, территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, муниципаль район халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

14) гомуми файдаланыштагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен, гражданнарның гомуми файдаланыштагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне дә кертеп, шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү.

4. Муниципаль районның җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт милке чикләнмәгән һәм муниципаль район составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

5. Әлеге статьяның 1 – 4 өлешләрендә билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда муниципаль районның җирле үзидарә органнары товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга вәкаләтле.»;

19) $16^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

20) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 статья. **Халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча шәһәр округы җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 1 өлеше нигезендә шәһәр округы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) шәһәр округы уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, муниципаль хокукый актлар чыгару;

2) шәһәр округының рәсми символларын билгеләү;

3) шәһәр округы бюджеты проектын төзү һәм карау, шәһәр округы бюджетын раслау һәм үтәү, муниципаль финанс контролен, шул исәптән шәһәр округы бюджеты үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә шәһәр округы бюджеты үтәлеше турында хисап төзү һәм раслау;

4) шәһәр округының муниципаль милкендәге мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

5) салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә шәһәр округы салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, гамәлгә кертү, элек кертелгән җирле салымнарын һәм җыемнарын гамәлдән чыгару;

6) гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәһәр округы территориясендә

(башкарма хакимиятнең халкы аерым территорияләр халкын медик-санитар тәэмин итү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы карамагындагы медицина оешмаларында медицина ярдәме белән тәэмин ителә торган территорияләнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән территорияләрдән гайре) гражданнарның сәламәтлеген саклауны гамәлгә ашыруда, шул исәптән халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыруда катнашу;

7) муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыру ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү;

8) ишегалды эчендәге территорияләрне үстерү;

9) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, шәһәр округы халкына рәсми мәгълүматны җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын гамәлгә кую;

10) муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзү, муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү һәм бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс белән тәэмин итү;

11) муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр күрсәтә торган хезмәтләргә, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр башкара торган эшләргә тарифлар билгеләү, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса;

12) шәһәр округы чикләрендә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру;

13) террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук шәһәр округы чикләрендә терроризм һәм экстремизм чагылышларын минимальләштерүдә һәм (яисә) алардан килгән зыяннарны бетерүдә катнашу;

14) шәһәр округы чикләрендәге гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм алардан килгән зыяннарны бетерүдә катнашу;

15) шәһәр округы территориясендәге муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

16) «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыру;

17) халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләре буенча кабул ителгән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру.

2. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлеше нигезендә шәһәр округы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә шәһәр округы чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

2) шәһәр округында яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, күпфатирлы йортта урыннарны үзгәртеп коруны һәм яңадан планлаштыруны килештерү турында

карар кабул итү, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

3) полициянең участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә шәһәр округының хезмәт күрсәтелә торган административ участогында эшләү өчен бина бирү;

4) муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне (федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне (финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш) оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программалары нигезендә өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карап торуны һәм карауны, карап тотуны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

5) шәһәр округы территориясендә физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, шул исәптән массакүләм спортны үстерүгә һәм аның һәркем өчен мөмкинлеген тәэмин итүгә ярдәм итү, балалар-яшүсмерләр спортын (мәктәп спортын да кертеп) үстерү, шәһәр округының рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү;

6) каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү чараларын, аларның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп, үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыру;

7) шәһәр округы халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

8) муниципаль архивны булдыру һәм тоту;

9) халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, шәһәр округы китапханәләренең китапханә фондларын туплау һәм аларның сакланышын тәэмин итү;

10) җирләү урыннарын карап тоту;

11) адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр,шәһәр округы чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыру;

12) шәһәр округы территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

13) шәһәр округы территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез мөлкәт объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча карарлар кабул итү һәм чаралар үткәрү, әлеге күчемсез мөлкәт объектларының хокук ияләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен җибәрү;

14) шәһәр округы ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре төзү өчен кирәкле эшләрне федераль закон нигезендә башкаруны тәэмин итү;

15) шәһәр округы милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру;

16) шәһәр округының икътисады һәм социаль өлкәсе торышын характерлый торган статистик күрсәткечләрне җыюны оештыру һәм аларны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыру;

17) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру;

18) муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрнең муниципаль хезмәткәрләренә һөнәри белем бирүне һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыру;

19) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, шәһәр округы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләренә һәм мәдәниятенә ярдәм итүгә һәм аларны үстерүгә, азсанлы милләтләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (халыкара) низагларны профилактикалауга юнәлтелгән гамәлләрне уйлап табу һәм тормышка ашыру;

20) җирле традицион халык сәнгать иҗаты үсеше өчен шартлар тудыру, шәһәр округындагы халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу;

21) шәһәр округы чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

22) шәһәр округы халкын мәдәният оешмалары, шәһәр округы халкының ялын, күпләп ялын оештыру хезмәтләре белән тәэмин итү, халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү өчен шартлар тудыру;

23) шәһәр округы милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклап калу, алардан файдалану һәм популярлаштыру, шәһәр округы территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклау;

24) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыру;

25) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү;

26) социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм ихтыяр белдерүгә (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтү;

27) шәһәр округы территориясендә гамәлгә ашырыла торган фәнни, фәнни-техник һәм инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү, шәһәр округының фәнне популярлаштыруга юнәлдерелгән программаларын кабул итү, чараларын оештыру һәм үткәрү;

28) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, шәһәр округында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

29) Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль контрольнең түбәндәге төрләрен гамәлгә ашыру:

а) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың йөкләмәләрен үтәвенә муниципаль контроль;

б) предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән, шул исәптән инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәүдән гыйбарәт булган Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында (куркынычсызлык мониторингы) күрсәтмә бирелергә мөмкин);

в) җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контроль;

г) шәһәр округы территорияләре составына керүче торак пунктлар чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль;

д) шәһәр округы чикләрендә муниципаль җир контроле;

е) муниципаль урман контроле.

3. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 3 һәм 7 өлешләре нигезендә шәһәр округы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) шәһәр округы чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) төзүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне дә кертеп, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыру;

2) халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм шәһәр округы чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

3) аларга карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларын, транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү

программаларын, шәһәр округының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшләү һәм раслау;

4) шәһәр округы чикләрендә әйләнә-тирә мохитне саклау гамәлләрен оештыру, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле шәһәр округы территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү;

5) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программаларны раслау һәм гамәлгә ашыру, алардагы урыннар шәһәр округы чикләрендәге муниципаль торак фондын тәшкил итә торган күпфатирлы йортларга энергетик тикшерү уздыруны оештыру, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда каралган башка чараларны оештыру һәм үткәрү;

6) ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру;

7) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым-аерым туплау), җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;

8) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карап чыгуларны гамәлгә ашыру һәм мондый карап чыгулар барышында ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирү, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының төзелешне планлаштыру турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килү һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итү турында хәбәрнамә юллау, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килмәү һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итмәү турында хәбәрнамә, төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының шәһәр округы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә урнашкан индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамәләр, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны тиешле таләпләргә туры китерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерүне гамәлгә ашыру яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда тиешле таләпләргә туры китерү, капиталь төзелеш объектын авария хәлендә дип тану һәм аның сүтелергә тиешлеге йә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда реконструкцияләнергә тиешлеге турында карар кабул итү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $5^1$ статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар уздыру;

9) җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның икенче төренә үзгәртү турында карар кабул итү, хосусый милектәге

җир кишәрлекләрен, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, бер категориядән икенче категориягә күчерү турында карар кабул итү;

10) федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;

11) шәһәр округы территорияләре составына керүче торак пунктлар җирләрендә урнашкан кишәрлек урманчылыклары составында төзелә торган урманчылыкларны төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук шәһәр округы территорияләре составына керүче торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру;

12) шәһәр округы территорияләре составына керүче торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше чараларын гамәлгә ашыру;

13) Реклама турында Россия Федерациясе законнары нигезендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау, шәһәр округы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтләр бирү, мондый рөхсәтләрне юкка чыгару, шәһәр округы территориясендә рөхсәтсез урнаштырылган реклама конструкцияләрен демонтажлау турында күрсәтмәләр бирү;

14) гражданнар оборонасы объектларыннан файдалануга даими әзерлек халәтендә ярдәм итүне, гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм тотуны да кертеп, территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, җирлек халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

15) су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

16) гомуми файдаланыштагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен, гражданнарның гомуми файдаланыштагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне дә кертеп, шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү;

17) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру.

4. Шәһәр округының җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә шәһәр округы территориясендә урнашкан һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

5. Әлеге статьяның 1 – 4 өлешләрендә билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда шәһәр округының җирле үзидарә органнары товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга вәкаләтле.»;

21) $17^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$17^1$ статья. **Халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен әлеге Закон белән яңадан бүленгән вәкаләтләрне**

**гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү**

Әлеге Законның 15 статьясындагы 3 һәм 6 өлешләрендә, 16 статьясындагы 3 өлешендә һәм 17 статьясындагы 3 өлешендә каралган, җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен яңадан бүленгән вәкаләтләрне финанслау Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле аерым федераль һәм (яисә) региональ салымнар һәм җыемнардан, махсус салым режимнарында каралган салымнардан, салым булмаган керемнәрдән түләүләрнең бердәм, өстәмә һәм (яисә) дифференциацияләнгән нормативларын исәпкә алып, муниципаль берәмлекләр бюджетларына тапшырыла торган җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Әлеге Законның 15 статьясындагы 3 һәм 6 өлешләрендә, 16 статьясындагы 3 өлешендә һәм 17 статьясындагы 3 өлешендә җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен яңадан бүленгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә рәвештә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.»;

22) 18 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

23) 19 статьяда:

а) 1 өлештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «һәм «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон» сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән субвенцияләр исәбенә гамәлгә ашырыла.»;

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле үзидарә органнары үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә үзләренең мөлкәтләреннән (матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан) өстәмә файдаланырга хокуклы.»;

г) 7 өлештә «органнары» сүзеннән соң «федераль закон нигезендә» сүзләрен өстәргә, «әлеге максатлар өчен бирелгән матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан» сүзләрен «әлеге максатлар өчен бирелгән мөлкәттән» сүзләренә алмаштырырга;

24) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге $19^1$ статьяны өстәргә:

«$19^1$ статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылмаган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашуы**

1. Җирле үзидарә органнары, федераль законнарда күрсәтелгән хокукны билгели торган нигезләмәләр булуга карамастан, аерым категория гражданнар өчен муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән (максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыруга җирле бюджетка тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) өстәмә социаль яклау һәм социаль ярдәм чаралары билгеләргә хокуклы.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган вәкаләтләрне финанслау муниципаль берәмлекнең бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан өстәмә акчалар бүлеп бирү өчен нигез булып тормый.»;

25) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге $19^2$ статьяны өстәргә:

«$19^2$ статья. **Җирле үзидарә органнарының җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелмәгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокуклары**

1. Җирле үзидарә органнары халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелмәгән вәкаләтләрне җирле бюджетлар керемнәре исәбенә башкарырга хокуклы, моңа Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлар һәм түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре керми.

2. Җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында федераль законнарда каралган стратегик планлаштыру өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслауны да кертеп;

2) муниципаль янгын сагын булдыру;

3) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру, ведомство карамагындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрүне федераль законнар нигезендә тикшереп тору;

4) югары белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын төзү;

5) туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;

6) муниципаль берәмлек музейларын булдыру;

7) инвалидларның, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләренә, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм күрсәтү;

8) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә ярдәм күрсәтү;

9) муниципаль берәмлек территориясе составына керә торган һәм аның административ үзәге булмаган торак пунктта нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр кылу;

10) Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы тарафыннан расланган халыкны кабул итү графигы нигезендә нотариус тарафыннан халыкны кабул итүне гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү;

11) торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү;

12) вәкаләтле участок полициясе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорына торак урын бирү;

13) муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

14) алкоголь, наркотик исереклегендә яисә башка төрле токсик исерек хәлдәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;

15) наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануны, наркоманияне профилактикалау чараларында катнашу;

16) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру;

17) «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнары каршында иҗтимагый советлар төзү;

18) муниципаль берәмлекнең бердәм дәүләт фәнни-техник сәясәтен үткәрүдә катнашуын тәэмин итү максатларында җирле үзидарә органнары каршында фәнни-техник советлар төзү.

2. Җирле үзидарә органнары халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелмәгән, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләрне җирле бюджетлар керемнәре исәбеннән гамәлгә ашырырга хокуклы, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан һәм түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән тыш.

3. Җирле үзидарә органнары, әгәр бу федераль законнарда каралган булса, башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга хокуклы.»;

26) 20 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. «Татарстан Республикасында халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруы рәвешләре «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә түбәндәгеләр була:

1) җирле референдум;

2) муниципаль сайлаулар;

3) гражданнар җыены»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 1[1] һәм 1[2] өлешләрне өстәргә:

«1[1]. Татарстан Республикасында җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашу рәвешләренә «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнардан сорашып белешү;

2) гавами тыңлаулар, җәмәгатьчелек фикер алышулары;

3) гражданнар җыелышы;

4) инициатив проектлар;

5) территориаль җәмәгать үзидарәсе;

6) авыл торак пункты старостасы.

1[2]. Халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруының һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуының «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда, әлеге Законда каралган рәвешләре белән беррәттән гражданнар җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда Россия Федерациясе Конституциясенә, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, башка федераль законнарга, әлеге Законга, Татарстан Республикасының башка законнарына каршы килми торган башка рәвешләрдә катнашырга хокуклылар.»;

в) 4 һәм 5 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) 5[1] өлештә «Гражданнардан сорашып белешү» сүзләрен «Гражданнардан сорашып белешүне, гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга, «муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

е) 7 өлешнең беренче абзацында «(вәкиллекле орган вәкаләтләрен башкара торган гражданнар җыены)» сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 8 өлешнең икенче абзацында «җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итүнең тиешле мәсьәләсен» сүзләренә алмаштырырга;

з) түбәндәге эчтәлектәге 9 һәм 10 өлешләрне өстәргә:

«9. Территориаль иҗтимагый үзидарәләргә, шул исәптән үз эшчәнлекләрен юридик зат буларак теркәлмичә гамәлгә ашыручыларга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары карарлары нигезендә җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән ярдәм күрсәтелергә мөмкин.

10. Авыл торак пункты старостасы статусының эшчәнлек гарантияләре һәм башка мәсьәләләре, шул исәптән старостаны матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү мәсьәләләре муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

27) 21 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарә органнары дигәндә халыкның яшәешен турыдан-туры

тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча үз вәкаләтләренә ия булган, халык тарафыннан турыдан-туры сайлана торган яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан төзелә торган органнар аңлашыла.»;

б) 2 өлештә «бары тик «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә генә рөхсәт ителә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә рөхсәт ителә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә «муниципаль берәмлекнең уставында каралган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләре булган җирле үзидарәнең башка органнары һәм урындагы сайланулы затлар тәшкил итә» сүзләрен «муниципаль берәмлек уставында каралган һәм халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча үз вәкаләтләренә ия башка органнар тәшкил итә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлешнең беренче абзацында «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләренә алмаштырырга;

д) 5 өлештә:

беренче абзацта «, аның структурасы җирле референдумда (сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең саны 300 кешедән артмаган муниципаль берәмлектә – гражданнар җыенында) халык тарафыннан билгеләнә яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы» сүзләрен «җирле үзидарә органнары структурасы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы сайлангач аның» сүзләренә алмаштырырга;

икенче – дүртенче азбзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутатларының саны, әлеге муниципаль берәмлекнең беренче башлыгын сайлау тәртибе, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

алтынчы абзацта «, әгәр федераль конституциячел законнарда башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләне төшереп калдырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары төзелгәнче, тиешле территорияләрдә яңа төзелгән муниципаль берәмлек халкының яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен яңа төзелгән муниципаль берәмлек төзелгән көнгә әлеге территорияләрдә халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашырган җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.»;

тугызынчы абзацта «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның

яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

е) 6 һәм 7 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

ж) тугызынчы өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм матди-техник яктан тәэмин итү, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, тиешле муниципаль берәмлекләр бюджетларының бары тик үз керемнәре исәбеннән генә гамәлгә ашырыла.»;

28) 22 статьяда:

а) 2 өлештә:

беренче абзацка түбәндәге эчтәлектәге җөмләне өстәргә: «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатлары үз вәкаләтләрен, кагыйдә буларак, даими булмаган нигездә гамәлгә ашыралар.»;

икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) $2^1$ һәм $2^2$ өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

в) 3 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

г) $3^1$ өлешнең 1 пунктындагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

д) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирлекнең, шәһәр округының вәкиллекле органының депутатлары саны «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм түбәндәгедән ким була алмый:

1) 7 кешедән – халык саны 1000 кешедән кимрәк булганда;

2) 10 кешедән – халык саны 1000 нән 10 000 кешегә кадәр булганда;

3) 15 кешедән – халык саны 10 000 нән 30 000 кешегә кадәр булганда;

4) 20 кешедән – халык саны 30 000 нән 100 000 кешегә кадәр булганда;

5) 25 кешедән – халык саны 100 000 нән 500 000 кешегә кадәр булганда;

6) 35 кешедән – халык саны 500 000 кешедән артык булганда.»;

е) түбәндәге эчтәлектәге $5^1$ һәм $5^2$ өлешләрне өстәргә:

«$5^1$. Муниципаль районның вәкиллекле органы депутатлары саны муниципаль район уставы белән билгеләнә һәм 15 кешедән ким була алмый.

$5^2$. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларының билгеләнгән саныннан 10 проценттан артык булмаган өлеше генә даими нигездә эшли ала, ә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының саны 10 кешедән кимрәк булса, - 1 депутат даими нигездә эшли ала.»;

ж) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларның билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе сайланган очракта тулы хокуклы составта сайланган дип санала.»;

з) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының үзенеке генә булган компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль берәмлек уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

2) җирле бюджетны һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

3) Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү, аларны гамәлгә кертү һәм элек кертелгән җирле салымнар һәм җыемнарны гамәлдән чыгару;

4) муниципаль берәмлекне социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау;

5) муниципаль милектәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен билгеләү;

6) муниципаль предприятиеләр төзү, аларны үзгәртеп кору һәм бетерү турында, шулай ук муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәтләре күрсәтүгә, эшләр башкаруга, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү;

7) җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

8) җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең урындагы затларының халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрен үтәүләрен тикшереп тору;

9) муниципаль берәмлек башлыгын «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган очракларда отставкага җибәрү турында карар кабул итү;

10) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;

11) муниципаль берәмлек башлыгының, җирле администрация башлыгының үз эшчәнлекләренең, җирле администрация һәм җирле үзидарәнең муниципаль берәмлек башлыгына буйсынган башка органнары эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында, шул исәптән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы алдына куелган мәсьәләләрне хәл итү турында еллык хисапларын тыңлау.»;

и) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарының башка вәкаләтләре федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасының законнары, муниципаль берәмлекләр уставлары белән билгеләнә.»;

к) 9[1] өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

л) 12 өлештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләренә алмаштырырга;

м) 15 өлештә «аерым юл белән» сүзләрен «башка чыгымнардан аерым» сүзләренә алмаштырырга;

29) 22[1] статьяда:

а) 2 өлештә «әлеге Закон,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 – 5, 10, 12 – 16 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

30) 23 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23 статья. **Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив һәм башка хокукый актлары**

1. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый актларына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль берәмлек уставын раслау турында норматив хокукый акт;

2) муниципаль берәмлек бюджетын раслау турында норматив хокукый акт;

3) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре;

4) җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне раслау турында норматив хокукый актлар;

5) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль берәмлек уставында үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабул ителгән башка норматив хокукый актлар.

2. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлек уставы белән үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча:

1) муниципаль берәмлек территориясендә үтәлүе мәҗбүри булган кагыйдәләрне билгели торган карарлар;

2) муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү турында карар;

3) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карарлар;

4) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлек уставы белән үз компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә.

3. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының салымнарны (җыемнарны) билгеләү, аларны гамәлгә кертү яисә гамәлдән чыгару, салым ставкаларын (җыемнар ставкаларын) үзгәртү, салымнарны (җыемнарны) түләү тәртибен һәм срогын үзгәртү турында, салым ташламаларын (җыемнар буенча ташламаларны) һәм (яисә) аларны куллану нигезләрен һәм тәртибен билгеләү (юкка чыгару) турында норматив хокукый актлары, муниципаль берәмлек вәкиллекле органының аларны финанс белән тәэмин итү җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны күздә тоткан норматив хокукый актларының башка проектлары җирле администрация башлыгы тәкъдиме буенча йә күрсәтелгән затның бәяләмәсе булганда муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан карала. Әлеге бәяләмә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына муниципаль берәмлек уставында билгеләнгән срокта тапшырыла һәм ул 20 көннән дә кимрәк була алмый.

4. Норматив хокукый актлар проектлары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатлары, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле үзидарәнең башка органнары, җирле администрация башлыгы, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре тарафыннан кертелә ала, шулай ук, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, муниципаль берәмлек уставында

билгеләнгән хокук чыгару инициативасының башка субъектлары тарафыннан кертелергә мөмкин.

5. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан карарлар кабул итү тәртибе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары, шул исәптән муниципаль берәмлек территориясендә үтәлү өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне билгели торган, шулай ук вәкиллекле орган эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карарлар, әгәр аның өчен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан кимрәге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала алмый.

6. Муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы кабул иткән норматив хокукый актка имза сала һәм аны халыкка җиткерә.

7. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы кабул иткән норматив хокукый акт 10 көн эчендә имза салу һәм халыкка җиткерү өчен муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

8. Муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы кабул иткән норматив хокукый актны кире кагарга хокуклы. Бу очракта күрсәтелгән норматив хокукый акт аны кире кагуның дәлилләнгән нигезләмәсе йә аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы тәкъдимнәр белән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына 10 көн эчендә кире кайтарыла.

9. Муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан кире кагылган норматив хокукый акт муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабат карала.

10. Кабат каралганда норматив хокукый акт муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесенең күпчелеге тарафыннан элеккеге редакциясендә расланса, аңа җиде көн эчендә муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имза салынырга һәм ул халыкка җиткерелергә тиеш.

11. Әлеге статьяның 8 – 10 өлешләре нигезләмәләренең гамәлдә булуы әлеге муниципаль берәмлек уставы нигезендә муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара торган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына кагылмый.»;

31) 24 статьяда:

а) 1 өлештә «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешнең 1 пунктындагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

в) $3^1$ өлешнең 1 пунктындагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

г) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль берәмлек башлыкларының махсус компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә муниципаль берәмлекне тәкъдим итү;

2) муниципаль берәмлек уставында билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларны имзалау, аларны халыкка игълан итү;

3) үз вәкаләтләре чикләрендә хокукый актлар чыгару;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының чираттан тыш утырышын чакыруны таләп итү хокукы.»;

д) түбәндәге эчтәлектәге 5¹ һәм 5² өлешләрне өстәргә:

«5¹. Муниципаль берәмлекләр башлыкларының башка вәкаләтләре федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлекләр уставлары белән билгеләнә.

5². Җирле администрацияне җитәкләүче муниципаль берәмлек башлыгы җирле үзидарә органнарының халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын тәэмин итә.»;

е) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлек уставы һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарлары белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә, муниципаль берәмлек уставы белән аның вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, шулай ук, әгәр муниципаль берәмлек башлыгы җирле администрация башлыгы вәкаләтләрен башкарса, әлеге Законның 26 статьясының 8 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләр буенча җирле администрация карарларын һәм күрсәтмәләрен чыгара.»;

ж) 8 өлештә ««Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

з) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Муниципаль берәмлек башлыгы сәламәтлеге торышына яисә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга вакытлыча комачаулый торган башка хәлләргә (аерым алганда, отпускка, хезмәт командировкасына) бәйле рәвештә үз вәкаләтләрен башкара алмаса, аның вәкаләтләрен вакытлыча муниципаль берәмлек уставы нигезендә билгеләнүче җирле үзидарәнең вазыйфаи заты башкара.»;

и) түбәндәге эчтәлектәге 12 -15 өлешләрне өстәргә:

«12. Татарстан Республикасы Рәисе түбәндәге очракларда муниципаль берәмлек башлыгын вазыйфасыннан алу турында хокукый акт чыгара:

1) муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына каршы килә торган норматив хокукый акт чыгарылганда, әгәр мондый каршы килүләр тиешле суд тарафыннан билгеләнгән булса, ә муниципаль берәмлек башлыгы суд карары үз көченә кергән көннән алып ике ай эчендә йә суд карарында каралган башка срок дәвамында үз вәкаләтләре чикләрендә суд карарын үтәү буенча чаралар күрмәсә;

2) муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан кеше һәм граждан хокукларын

һәм ирекләрен бозуга, Россия Федерациясенең бердәмлегенә һәм территориаль бөтенлегенә, Россия Федерациясенең милли иминлегенә һәм аның оборона сәләтенә, Россия Федерациясенең хокукый һәм икътисадый киңлегенең бердәмлегенә куркыныч тудыруга, максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлардан, бюджет кредитларыннан максатсыз файдалануга китерә торган гамәлләр кылынганда, шул исәптән аның тарафыннан норматив характердагы булмаган хокукый акт чыгарылганда, Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан алынган бюджетара трансфертлар, бюджет кредитлары бирү шартлары бозылганда, әгәр бу тиешле суд тарафыннан билгеләнгән булса, әмуниципаль берәмлек башлыгы үз вәкаләтләре чикләрендә суд карарын үтәү буенча чаралар күрмәсә.

13. Татарстан Республикасы Рәисенең муниципаль берәмлек башлыгын әлеге статьяның 12 өлеше нигезендә вазыйфасыннан алуы турында хокукый акт чыгару срогы судның күрсәтелгән хокукый актны чыгару өчен кирәкле соңгы карары үз көченә кергән көннән бер айдан да кимрәк була алмый һәм әлеге суд карары үз көченә кергән көннән алты айдан да артыграк була алмый.

14. Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфасыннан алырга хокуклы:

1) муниципаль берәмлек башлыгын, Татарстан Республикасы Рәисе «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 29 статьясындагы 7 өлеше нигезендә муниципаль берәмлек башлыгына кисәтү, шелтә белдергән көннән алып бер ай эчендә муниципаль берәмлек башлыгы кисәтү, шелтә белдерү өчен нигез булган сәбәпләрне бетерү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә чаралар күрмәгән очракта;

2) муниципаль берәмлек башлыгын, халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча әлеге Законның 15-17 статьяларында каралган вәкаләтләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны тәэмин итү бурычларын тиешенчә үтәмәгән яисә үтәмәгән өчен, шулай ук «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 21 статьясындагы 3 өлешенең 6 пунктында каралган нигез буенча, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы фикерен исәпкә алып, муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына керешкән көннән кимендә бер ел узгач;

3) муниципаль берәмлек башлыгын, әгәр Татарстан Республикасы Рәисе муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү турында инициативаны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына ике һәм аннан да күбрәк тапкыр керткән һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кире кагылган булса, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 21 статьясындагы 3 өлешендә каралган нигезләрнең берсе буенча, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» Ассоциациясе фикерен исәпкә алып, муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына керешкән көннән алып ике елдан да иртәрәк булмаган вакытта.

15. Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфасыннан алу турында хокукый акт чыгарылган муниципаль берәмлек башлыгы әлеге хокукый актка ул рәсми басылып чыккан көннән алып 10 көн эчендә суд тәртибендә шикаять бирергә

хокуклы.»;

32) түбәндәге эчтәлектәге 24[1] статьяны өстәргә:

«24[1] статья. **Муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы**

1. Муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы билгеләнү көненә Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турындагы законнар нигезендә пассив сайлау хокукына чикләүләре булмаган затлар арасыннан Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан 10 көн эчендә билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлек башлыгын сайлаган һәм ул үз вазыйфасына кергән көнгә кадәр түбәндәге очракларда билгеләп куела:

1) әгәр муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидат муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы муниципаль берәмлек башлыгын үз составыннан сайлау турында карар кабул итсен өчен кирәкле сандагы тавышны җыймаса;

2) муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату йә суд карары буенча аны сак астына алу яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылса.

2. Муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы муниципаль берәмлек башлыгы хокукларына һәм бурычларына ия була.

3. Муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы вәкаләтләре күләме муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыны билгеләп кую турында Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый акты белән чикләнергә мөмкин (әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда).

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләп куела торган муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыга коррупциягә каршы тору максатларында «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында муниципаль берәмлек башлыгы өчен билгеләнгән бурычлар, чикләүләр һәм тыюлар кагыла.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләп куела торган муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы муниципаль берәмлек башлыгы өчен билгеләнгән тәртиптә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра.

6. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләп куела торган муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы билгеләнгәннән соң 15 көн эчендә әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне өстәмә рәвештә тапшыра. Бу чакта билгеләнү елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган

керемнәр турында белешмәләр һәм билгеләнү көненә мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырыла.

7. Әлеге статьяның 4 - 6 өлешләрендә билгеләнгән таләпләрне бозу әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләп куела торган муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез булып тора.»;

33) 25 статьяда:

а) 1 өлештә «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле администрация структурасы җирле администрация башлыгы тәкъдиме беләң муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан раслана.

Тиешле территориядә яшәүче халык мәнфәгатьләрендәге мәсьәләләрне аеруча нәтиҗәле хәл итү максатларында җирле администрация структурасында түбәндәге критерийлар нигезендә җирле администрациянең территориаль органнары төзелергә мөмкин:

1) муниципаль берәмлек составына керүче барлык торак пунктларда яшәүчеләр өчен эш көне дәвамында муниципаль берәмлекнең административ үзәгенә яисә җирле администрациянең территориаль органнарына кадәр һәм кирегә җәяү барып җитү мөмкинлеге;

2) муниципаль берәмлек халкының саны 500 000нән артык кешене тәшкил итә.

Җирле администрация структурасында җирле администрациянең тармак (функциональ) органнары формалаштырылырга мөмкин.»;

34) 26 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «муниципаль берәмлек уставында билгеләнә торган вәкаләтләр чорына» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә:

беренче абзацта «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә:

өченче абзацның беренче җөмләсендә «Җирлекләрдә» сүзен «Җирлекнең җирле администрация башлыгы вазыйфасына кандидатура сайлауга конкурс уздырганда» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләдә «Муниципаль районда, шәһәр округында» сүзләрен «Муниципаль районда, шәһәр округында җирле администрация башлыгы вазыйфасына кандидатура сайлауга конкурс уздырганда» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «муниципаль районда конкурс комиссиясе төзегәндә» сүзләрен «муниципаль район башлыгы вазыйфасына кандидатура сайлауга конкурс уздырганда» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлешнең икенче абзацында «Җирле администрация башлыгы» сүзләре

алдыннан «Үз вәкаләтләрен конкурс нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашыручы» сүзләрен өстәргә;

д) $5^1$ өлештә:

беренче абзацта «контракт нигезендә» сүзләрен «конкурс нәтиҗәләре буенча» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) үзенә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу яисә чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алу йә яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документын алу турында мәгълүм булган көнне, ләкин Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан яисә чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алган йә яшәүгә рөхсәт яисә әлеге пунктта каралган бүтән документ алган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлек башлыгына бу хакта язмача хәбәр итәргә тиеш.»;

е) 6 өлештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 7 һәм $7^1$ өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

з) 8 өлештә «җирле әһәмияттәге мәсьәләләр» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

и) түбәндәге эчтәлектәге 10 – 13 өлешләрне өстәргә:

«10. Татарстан Республикасы Рәисе түбәндәге очракларда җирле администрация башлыгын вазыйфасыннан алу турында хокукый акт чыгара:

1) җирле администрация башлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына каршы килә торган норматив хокукый акт чыгарылганда, әгәр мондый каршылыклар тиешле суд тарафыннан билгеләнгән булса, ә җирле администрация башлыгы суд карары үз көченә кергән көннән алып ике ай эчендә йә суд карарында каралган башка срок дәвамында үз вәкаләтләре чикләрендә суд карарын үтәү буенча чаралар күрмәсә;

2) җирле администрация башлыгы тарафыннан кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозуга, Россия Федерациясенең бердәмлегенә һәм территориаль бөтенлегенә, Россия Федерациясенең милли иминлегенә һәм аның оборона сәләтенә, Россия Федерациясенең хокукый һәм икътисадый киңлегенең бердәмлегенә куркыныч тудыруга, максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлардан, бюджет кредитларыннан максатсыз файдалануга китерә торган гамәлләр кылынганда, шул исәптән аның тарафыннан норматив характердагы булмаган хокукый акт чыгарылганда, Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан алынган бюджетара трансфертлар, бюджет кредитлары бирү шартлары бозылганда, әгәр бу тиешле суд тарафыннан билгеләнгән булса, ә җирле администрация башлыгы үз вәкаләтләре чикләрендә суд карарын үтәү буенча чаралар күрмәсә.

11. Татарстан Республикасы Рәисенең җирле администрация башлыгын вазыйфасыннан азат итү турында әлеге статьяның 10 өлеше нигезендә хокукый акт чыгару срогы судның күрсәтелгән хокукый актны чыгару өчен кирәкле соңгы карары үз көченә кергән көннән бер айдан да кимрәк була алмый һәм әлеге суд карары үз көченә кергән көннән алты айдан да артыграк була алмый.

12. Татарстан Республикасы Рәисе «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 29 статьясындагы 7 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан җирле администрация башлыгына кисәтү, шелтә белдергән көннән алып бер ай эчендә җирле администрация башлыгы кисәтү, шелтә белдерү өчен нигез булган сәбәпләрне бетерү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә чаралар күрмәгән очракта җирле администрация башлыгын вазыйфасыннан азат итәргә хокуклы.

13. Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфасыннан китү турында хокукый акт чыгарылган җирле администрация башлыгы әлеге хокукый актка ул рәсми басылып чыккан көннән алып 10 көн эчендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

35) 27 статьяның 2 өлешендә «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыру һәм алар эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларының, федераль территорияләрнең һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыру һәм алар эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» сүзләренә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләренә алмаштырырга;

36) 29 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29 статья. **Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның статусы**»;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның статусы федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль берәмлекләр уставлары белән билгеләнә.»;

в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләр чоры биш ел тәшкил итә.»;

г) түбәндәге эчтәлектәге $2^1$ өлешне өстәргә:

«$2^1$. Әлеге статьяның 2 өлеше нигезләмәләре муниципаль вазыйфаны биләүче затның «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25 статьясында каралган вәкаләтләрен туктату тәртибенең үзенчәлекләрен исәпкә алып кулланыла.»;

д) 3 өлешнең беренче абзацында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясындагы 7 өлешенең» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне

оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясындагы 4 өлешенең» сүзләренә алмаштырырга;

е) 4 өлештә «эш урынын (вазыйфасын) саклап калу» сүзләрен «эш бирүче тарафыннан эш урынын (вазыйфасын) саклап калып эштән азат ителү» сүзләренә алмаштырырга;

37) 30 статьяда «таләпләрне» сүзен «таләпләр куюны» сүзләренә алмаштырырга;

38) 31 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарәнең икътисадый нигезен муниципаль милектәге мөлкәт, шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең мөлкәти хокуклары, шулай ук җирле бюджетлар акчалары тәшкил итә.»;

39) 32 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль милектә булырга мөмкин булган мөлкәт «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль закон белән билгеләнә.»;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле үзидарә органнары мөлкәтне муниципаль милеккә сатып алырга, муниципаль мөлкәтне физик һәм юридик затларга, гавами хакимият органнарына, шул исәптән башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вакытлыча хуҗалык итүгә һәм (яисә) файдалануга тапшырырга, аны аерып куярга, федераль законнар нигезендә башка төрле алыш-бирешләр ясарга хокуклы.»;

в) түбәндәге эчтәлектәге 6 һәм 7 өлешләрне өстәргә:

«6. Муниципаль берәмлекләр муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзи алалар, хуҗалык җәмгыятьләре, шул исәптән халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципальара җәмгыятьләр төзүдә катнаша алалар. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары башкара.

7. Җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль казна учреждениеләре йөкләмәләре буенча субсидиялэтә җавап бирәләр һәм күрсәтелгән йөкләмәләрнең үтәлешен федераль законда билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәләр.»;

40) 33 статьяның 6 өлешендәге икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

41) 35 статьяда:

а) 1 өлештә «җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итүнең конкрет мәсьәләләрен» сүзләренә, «(җирлек, шәһәр округы составына керүче торак пунктта (йә аның территориясе өлешендә)» сүзләрен «(муниципаль берәмлек территориясе составына керүче торак пунктта (торак пункт территориясе өлешендә)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $25^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 4, $4^{1}$ һәм $4^{3}$ пунктларында» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 45 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

42) 42 – 44 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

43) 45 статьяның 2 өлешендә «, әгәр «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә;

44) $49^{1}$ статьяда:

а) 1 өлештә «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлешнең 3 пунктында «җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләне» сүзләрен «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итүнең конкрет мәсьәләсен» сүзләренә алмаштырырга;

45) 53 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

46) $53^{1}$ статьяда «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

47) 54 статьяда «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

48) 55 статьяда «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар» сүзләрен «федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

49) 56 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

50) 58 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

51) 1 нче кушымтаның исемендә «, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау» сүзләрен төшереп калдырырга;

52) 2 нче кушымтада «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы

Федераль законның 40 статьясындагы 7 өлешенең (муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата)» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 4 өлешенең» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә, әлеге Законның 1 статьясындагы 15 – 23 һәм 25 пунктларыннан тыш.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 15 – 23 һәм 25 пунктлары 2028 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләү «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында Федераль закон) үз көченә керүенә (2025 елның 19 июненнән һәм тулы күләмдә 2028 елның 1 гыйнварыннан) бәйле.

Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы Федераль закон 2027 елның 1 гыйнварына кадәр региональ һәм муниципаль норматив хокукый актларны аңа туры китерүне күздә тота.

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) гомуми нигезләмәләргә кагылышлы 1 бүлегендә аерым алганда «җирле үзидарә» төшенчәсенә, муниципаль хокукый актлар системасын ачучы нормаларга, муниципаль берәмлекләр уставларын кабул итү һәм муниципаль норматив хокукый актларның үз көченә керү тәртибенә төзәтмәләр кертелде (элеккеге кебек, тулаем халыкка чыгарылмыйча, рәсми басылып чыкканнан соң үз көчләренә керәләр).

Бүлеккә «Җирле үзидарәне хокукый җайга салу принциплары»н билгели торган 4¹ статья өстәлде. Күрсәтелгән статьяда җирле үзидарә органнарына гавами хакимиятнең бердәм системасы органнары белән дистанцион хезмәттәшлек тәртибен һәм вәкиллекле органнар утырышларында читтән торып катнашу форматын мөстәкыйль билгеләү хокукы бирелә.

Моннан тыш, беренче һәм аннан соңгы бүлекләрдә:

эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турындагы таләпләр төшереп калдырыла (аны гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында);

гражданнар җыены вәкаләтләреннән вәкиллекле орган булмаганда аның функцияләрен үтәү төшереп калдырыла;

редакцион төзәтмәләр кертелә, мәсәлән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга сылтамаларны Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында Федераль законга сылтамаларга алмаштыра торган, «халыкның яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләре» (элек - җирле әһәмияттәге мәсьәләләр) төшенчәсен ачыклый торган, һ.б.

Республикада җирле үзидарәне территориаль оештыруны ачыклаучы бүлектә,

муниципаль берәмлекләрнең төрләренә һәм чикләренә багышланган 12 һәм 13 статьяларның структурасы Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында Федераль закон структурасына туры китерелде. 14 статьяда муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору төрләре исемлегеннән шәһәр эчендәге бүленеше булган шәһәр округыннан шәһәр эчендәге районны аерып чыгару төшереп калдырылды.

Закон проекты тәкъдим итә торган редакциядә 3 бүлектә җирле үзидарә органнарының җирлек, муниципаль район һәм шәһәр округы халкының яшәешен турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләре билгеләнә.

4 бүлекнең 20 статьясында халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу рәвешләре исемлегеннән депутатны, сайланулы орган әгъзасын һәм җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу буенча тавыш бирү, муниципалитетлар чикләрендә тавыш бирү, хокук иҗат итү инициативасы һәм гражданнар конференциясе кебек механизмнар төшереп калдырылган.

Моннан тыш, закон проекты территориаль иҗтимагый үзидарәләргә Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар хисабына финанс ярдәме күрсәтү мөмкинлеген күздә тота.

Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлеген регламентлаучы бишенче бүлеккә шулай ук кайбер үзгәрешләр кертү каралган.

22 статьяда муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органы составының минималь санын билгели торган норма каралган, шулай ук вәкиллекле органның махсус компетенциясенә керә торган мәсьәләләргә төзәтмәләр кертелгән.

24 һәм 25 статьяларда муниципаль берәмлекләр башлыкларын һәм башкарма комитетлар җитәкчеләрен Татарстан Республикасы Рәисе инициативасы белән вазыйфаларыннан азат итү тәртибе каралган.

Шулай ук проект тарафыннан муниципаль берәмлекләр башлыклары вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыларны билгеләүнең яңа кагыйдәләрен регламентлаштыра торган $24^1$ статья кертелә.

Икътисадый нигезләргә, халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләргә, гарантияләргә, җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының җаваплылыгына кагылышлы бүлекләргә, йомгаклау һәм күчеш нигезләмәләренә, шулай ук Законга кушымталарга редакцион төзәтмәләр кертү каралган.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.